**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2020 елның 21 июленнән** № **141**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге депутаты, җирле үзидарәнең
сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы
вазыйфаи заты вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә
ашыручы затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә
чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган
акчалата бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү хакында" 2013 елның 17 июлендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. Иске Гришкино авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 апрелендәге 100 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында карарына түбәндәге үзгәрешләәрне кертергә:
1.1. 2 нче кушымтаның 2 пунктындагы 2 абзацы үз көчен югалткан дип санарга:
1.2. 2 нче кушымтаның 1 пунктында «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә» сүзләрен «муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән " сүзләренә алмаштырырга
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чвгырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru "Иске гришкино авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Иске Гришкино авыл җирлеге
Советы Рәисе В.В. Мамакова